| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯР БУЕ МОРКВАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.12.2019 с. Набережные Моркваши № 20

Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлегендә урнашкан су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларын тикшерү һәм категорияләү буенча комиссия төзү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 23 декабрендәге 1467нче номерлы «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларының террорчылыкка каршы яклануына карата таләпләрне, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларының куркынычсызлык паспортының формасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларының террорчылыкка каршы яклануына карата таләпләр нигезендә

КАРАР БИРӘМ

1.1. Югары Ослан муниципаль районы Яр Буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә урнашкан су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларын карау һәм категорияләү буенча түбәндәге составта комиссия төзергә:

| № | ФИО | Вазифа |
|---|---|---|
| Комиссия рәисе | | |
| 1 | Гаязов Ильнур Хазинурович | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы |
| Комиссия әгъзалары | | |
| 2 | Мартынов Дмитрий Алевтинович | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Зеленодольский шәһәрендәге идарәсе |
| 3 | Гайнуллин Айдар Дамирович | «Россия УВО ВНГ Татарстан Республикасы буенча» ПЦО ОВО |

| | | |
|---|---|---|
| | | Зеленодольский районы буенча ФГКУфилиалы начальнигы |
| 4 | Садыков Анас Дамирович | Татарстан Республикасы буенча РФ ГТХМ Баш идарәсенең Югары Ослан муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге башлыгы |

2. Комиссия үз эше барышында:

а) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектында террор актлары кылу куркынычы дәрәҗәсен билгели;

б) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектының конструктив һәм

техник характеристикаларын, аның эшчәнлеген оештыруны, су белән тәэмин итү

һәм ташландык суларны агызу объектының куркынычсыз эшләвен тәэмин итү буенча гамәлдәге чараларны өйрәнә;

в) инфраструктура һәм яшәү тәэмин итү өчен су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектының әһәмиятен билгели;

г) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектының критик элементларын ачыклый;

д) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектында террор актлары кылуның ихтимал нәтиҗәләрен билгели;

е) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектының категориясен билгели яки элек бирелгән категорияне раслый (үзгәртә) ;

ж) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектын аның категориясе нигезендә террорчылыктан саклангалыгы торышына тикшерү үткәрә;

з) аның категориясен исәпкә алып, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектының террорчылыкка каршы яклануын тәэмин итү чараларын, шулай ук әлеге чараларны гамәлгә ашыру вакытын, планлаштырылган эшләр һәм финанслау чыганакларын исәпкә алып, билгели.

3. Комиссия эшенең нәтиҗәләре кушымта нигезендә объектны тикшерү һәм категорияләү акты белән рәсмиләштерелә.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ____________И.Х.Гаязов